**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июня 2025 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 27 (часть I), № 55 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 36 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 17 (часть I), № 24 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 73 (часть I), № 81 (часть I), № 92 (часть I), № 96 (часть I); 2024, № 18 (часть I), № 47 (часть I), № 56 (часть I), № 76 (часть I), № 79 (часть I), № 93 (часть I); 2025, № 18 (часть I) следующие изменения:

1) часть 10 статьи 22 изложить в следующей редакции:

«10. Организацию деятельности представительного органа муниципального образования в соответствии с уставом муниципального образования осуществляет председатель представительного органа муниципального образования, избираемый этим органом из своего состава, а в случае, если в соответствии со статьей 24 настоящего Закона глава муниципального образования исполняет полномочия

председателя представительного органа муниципального образования, – глава муниципального образования.»;

2) в статье 24:

а) дополнить частью 2[1] следующего содержания:

«2[1]. Глава муниципального образования города Казани избирается представительным органом муниципального образования города Казани из числа кандидатов, представленных Главой (Раисом) Республики Татарстан.

Порядок предварительного рассмотрения Главой (Раисом) Республики Татарстан и представления представительному органу муниципального образования города Казани кандидатов на должность главы муниципального образования города Казани устанавливается приложением 4 к настоящему Закону.

Глава муниципального образования города Казани, являющийся депутатом представительного органа муниципального образования города Казани, исполняет полномочия председателя указанного органа.

Глава муниципального образования города Казани не может одновременно исполнять полномочия председателя представительного органа муниципального образования и полномочия главы местной администрации.»;

б) абзац первый части 3 изложить в следующей редакции:

«3. Глава муниципального образования, которое имеет статус муниципального района, городского округа, за исключением главы муниципального образования города Казани, или городского поселения и органы местного самоуправления которого наделены законом Республики Татарстан отдельными государственными полномочиями, а также глава муниципального образования, которое имеет статус городского поселения и включает в состав территории населенный пункт, являющийся административным центром муниципального района, либо на территории которого в соответствии с законом Республики Татарстан находится место постоянного пребывания мирового судьи Республики Татарстан:»;

в) в абзаце первом части 3[1] слова «в части 3» заменить словами «в частях 2[1] и 3»;

3) дополнить приложением 4 следующего содержания:

«Приложение 4
к Закону Республики Татарстан
«О местном самоуправлении
в Республике Татарстан»

**Порядок**
**предварительного рассмотрения Главой (Раисом) Республики Татарстан и представления представительному органу муниципального образования города Казани кандидатов на должность главы муниципального образования города Казани**

1. Предложения о кандидатурах на должность главы муниципального образования города Казани (далее – глава муниципального образования) вправе

вносить Главе (Раису) Республики Татарстан политические партии, федеральные списки кандидатов которых на основании официально опубликованных результатов ближайших предыдущих выборов депутатов Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации допущены к распределению депутатских мандатов, политические партии, списки кандидатов которых были допущены к распределению депутатских мандатов в действующем на день внесения Главе (Раису) Республики Татарстан указанных предложений Государственном Совете Республики Татарстан, Ассоциация «Совет муниципальных образований Республики Татарстан», Общественная палата Республики Татарстан, Ассоциация «Всероссийская ассоциация развития местного самоуправления».

2. Информация о сборе предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования, сроке и месте внесения указанных предложений опубликовывается в средствах массовой информации, а также размещается на официальном сайте Главы (Раиса) Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

3. Кандидатом на должность главы муниципального образования (далее – кандидат) может быть гражданин, который на день представления представительному органу муниципального образования города Казани (далее – представительный орган) кандидатов не имеет в соответствии с законодательством об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации ограничений пассивного избирательного права.

4. Лицо, выдвинутое в качестве кандидата, представляет Главе (Раису) Республики Татарстан заявление в письменной форме о своем согласии быть кандидатом с обязательством в случае его избрания прекратить деятельность, несовместимую со статусом главы муниципального образования.

В заявлении указываются фамилия, имя, отчество (при наличии), дата и место рождения, адрес места жительства, серия, номер и дата выдачи паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина, наименование или код органа, выдавшего паспорт или документ, заменяющий паспорт гражданина, идентификационный номер налогоплательщика (при наличии), страховой номер индивидуального лицевого счета, гражданство, сведения о профессиональном образовании (при наличии) с указанием организации, осуществляющей образовательную деятельность, года ее окончания и реквизитов документа об образовании и о квалификации, основное место работы или службы, занимаемая должность (в случае отсутствия основного места работы или службы – род занятий), принадлежность к политической партии кандидата, сведения о том, является ли кандидат депутатом представительного органа, имелась или имеется ли у кандидата судимость (если судимость снята или погашена, – сведения о дате снятия или погашения судимости), является ли кандидат иностранным агентом или лицом, аффилированным с иностранным агентом.

5. Вместе с заявлением, предусмотренным пунктом 4 настоящего Порядка, представляются:

1) заверенная кандидатом копия паспорта или документа, заменяющего паспорт гражданина;

2) заверенные кандидатом копии документов, подтверждающих указанные в заявлении сведения об образовании, основном месте работы или службы, о занимаемой должности (роде занятий), а в случае, если кандидат является депутатом представительного органа, – также о том, что кандидат является депутатом;

3) если кандидат менял фамилию, или имя, или отчество, – заверенные кандидатом копии соответствующих документов;

4) сведения о размере и об источниках доходов кандидата, его супруга (супруги) и несовершеннолетних детей, об имуществе, принадлежащем им на праве собственности, а также о счетах, вкладах в банках, ценных бумагах по состоянию на первое число месяца, в котором Главе (Раису) Республики Татарстан вносится предложение о кандидатуре на должность главы муниципального образования, по форме, предусмотренной Федеральным законом от 12 июня 2002 года № 67-ФЗ «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации»;

5) справка о принадлежащем кандидату, его супругу (супруге) и несовершеннолетним детям недвижимом имуществе, находящемся за пределами территории Российской Федерации, об источниках получения средств, за счет которых приобретено указанное имущество, об их обязательствах имущественного характера за пределами территории Российской Федерации по форме, утвержденной Указом Президента Российской Федерации от 6 июня 2013 года № 546 «О проверке достоверности сведений об имуществе и обязательствах имущественного характера за пределами территории Российской Федерации, о расходах по каждой сделке по приобретению объектов недвижимости, транспортных средств, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), цифровых финансовых активов, цифровой валюты, представляемых кандидатами на выборах в органы государственной власти, выборах глав муниципальных районов, глав муниципальных округов и глав городских округов, а также политическими партиями в связи с внесением Президенту Российской Федерации предложений о кандидатурах на должность высшего должностного лица субъекта Российской Федерации»;

6) справка о расходах кандидата, его супруга (супруги) и несовершеннолетних детей по каждой сделке по приобретению земельного участка, другого объекта недвижимости, транспортного средства, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), цифровых финансовых активов, цифровой валюты, совершенной в течение последних трех лет, если сумма сделки превышает общий доход кандидата и его супруга (супруги) за три последних года, предшествующих совершению сделки, и об источниках получения средств, за счет которых совершена сделка, по форме, утвержденной Указом Президента Российской Федерации от 6 июня 2013 года № 546 «О проверке достоверности сведений об имуществе и обязательствах имущественного характера за пределами территории Российской Федерации, о расходах по каждой сделке по приобретению объектов недвижимости, транспортных средств, ценных бумаг (долей участия, паев в уставных (складочных) капиталах организаций), цифровых финансовых активов, цифровой валюты, представляемых кандидатами на выборах в органы государственной власти, выборах глав муниципальных районов, глав

муниципальных округов и глав городских округов, а также политическими партиями в связи с внесением Президенту Российской Федерации предложений о кандидатурах на должность высшего должностного лица субъекта Российской Федерации»;

7) копия устава организации, внесшей предложение о кандидатуре на должность главы муниципального образования, заверенная постоянно действующим руководящим органом данной организации;

8) копия решения органа организации, внесшей предложение о кандидатуре на должность главы муниципального образования, уполномоченного в соответствии с уставом данной организации на принятие такого решения, заверенная постоянно действующим руководящим органом данной организации;

9) согласие кандидата на обработку его персональных данных.

6. Для предварительного рассмотрения предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования Главой (Раисом) Республики Татарстан образуется комиссия по предварительному рассмотрению предложений о кандидатурах на должность главы муниципального образования (далее – комиссия).

7. Численный и персональный состав комиссии утверждается Главой (Раисом) Республики Татарстан.

8. Комиссия организует проверку достоверности документов и сведений, представленных в соответствии с пунктами 4 и 5 настоящего Порядка, в том числе путем направления запросов в соответствующие государственные органы и иные организации в установленном порядке.

9. Кандидаты могут быть приглашены на заседание комиссии для проведения собеседования.

10. В случае если в процессе проверки документов и сведений установлена их недостоверность, комиссия уведомляет кандидата об отклонении его кандидатуры на должность главы муниципального образования.

11. По каждому из кандидатов, не отклоненных в соответствии с пунктом 10 настоящего Порядка, комиссией проводится рейтинговое голосование.

12. Рейтинговое голосование представляет собой ряд последовательных голосований членов комиссии по каждому из кандидатов персонально.

13. По итогам рейтингового голосования комиссией на рассмотрение Главы (Раиса) Республики Татарстан представляется не менее двух и не более пяти кандидатов для принятия окончательного решения.

14. Главой (Раисом) Республики Татарстан утверждается и представляется представительному органу не менее двух кандидатов для избрания главы муниципального образования.».

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Абзац третий части $2^1$ статьи 24 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (в редакции настоящего Закона) применяется в отношении главы муниципального

образования города Казани, осуществляющего полномочия председателя представительного органа муниципального образования, до истечения срока полномочий представительного органа муниципального образования города Казани, избранного до 1 января 2027 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан | Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ •

Казань, Кремль
25 июня 2025 года
№ 45-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 22 статьяның 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Муниципаль берәмлек уставы нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы эшчәнлеген оештыруны – муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан үз составыннан сайлап куела торган шул орган рәисе, әгәр әлеге Законның 24 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль

бермлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкарса, муниципаль берәмлек башлыгы гамәлгә ашыра.»;

2) 24 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле 2$^{1}$ өлеш өстәргә:

«2$^{1}$. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан сайлап куела.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатларны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алдан карау һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына тәкъдим итү тәртибе әлеге Законга 4 нче кушымтада билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы депутаты булып торучы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы күрсәтелгән орган рәисе вәкаләтләрен башкара.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен һәм җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен берьюлы башкара алмый.»;

б) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгыннан тыш, муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге статусындагы һәм җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы законы белән аерым дәүләт вәкаләтләре бирелгән муниципаль берәмлек башлыгы, шулай ук шәһәр җирлеге статусындагы һәм территориясе составына муниципаль районның административ үзәге булып торучы торак пункт кергән йә территориясендә Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы җәмәгать судьясының даими булу урыны булган муниципаль берәмлек башлыгы:»;

в) 3$^{1}$ өлешнең беренче абзацында «3 өлешендә» сүзләрен «2$^{1}$ һәм 3 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле 4 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы вазыйфасына кандидатларны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан алдан карау һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына тәкъдим итү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Рәисенә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (алга таба – муниципаль берәмлек башлыгы) вазыйфасына кандидатуралар

турында тәкъдимнәрне кандидатларның федераль исемлекләре Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын узган иң якын сайлауларның рәсми басылып чыккан нәтиҗәләре нигезендә депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сәяси партияләр, кандидатларның исемлекләре күрсәтелгән тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Рәисенә кертү көненә гамәлдә булган Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән сәяси партияләр, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, «Җирле үзидарәне үстерү бөтенроссия ассоциациясе» ассоциациясе кертергә хокуклы.

2. Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр җыю, күрсәтелгән тәкъдимнәрне кертү сроклары һәм урыны хакында мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына (алга таба – вәкиллекле орган) кандидатлар тәкъдим итү көненә Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында законнар нигезендә пассив сайлау хокукына чикләүләр булмаган граждан муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидат (алга таба – кандидат) була ала.

4. Кандидат буларак күрсәтелгән зат үзенең сайлануы очрагында муниципаль берәмлек башлыгы статусына туры килми торган эшчәнлеген туктатуы йөкләмәсе белән кандидат булырга ризалык бирүе турында Татарстан Республикасы Рәисенә язмача гариза тапшыра.

Гаризада кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы һәм урыны, яшәү урынының адресы, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе, номеры һәм бирелү датасы, паспортын яисә граждан паспортын алмаштыручы документны биргән органның исеме яисә коды, салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта), индивидуаль шәхси счетның иминият номеры, гражданлыгы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы, аны тәмамлау елын, белем һәм квалификация турындагы документының реквизитларын күрсәтеп, һөнәри белем турында (булган очракта) белешмәләр, төп эш яисә хезмәт итү урыны, биләгән вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт итү урыны булмаган очракта – шөгыльләренең төре), сәяси партиядә торуы, кандидатның вәкиллекле орган депутаты булу-булмавы, кандидатның элек яисә хәзер хөкем ителгән булу-булмавы (әгәр хөкем ителүе юкка чыгарылган яисә кире алынган булса, – хөкем ителүне юкка чыгару яисә кире алу датасы турында белешмәләр), кандидатның чит ил агенты яисә чит ил агенты белән аффилиацияләнгән зат булу-булмавы турында белешмәләр күрсәтелә.

5. Әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) паспортның яисә граждан паспортын алмаштыручы документның кандидат тарафыннан таныкланган күчермәсе;

2) гаризада күрсәтелгән белеме, төп эш яисә хезмәт итү урыны, били торган вазыйфасы (шөгыльләренең төре) турында, ә кандидат вәкиллекле орган депутаты булып торган очракта, – шулай ук кандидатның депутат булуы турында белешмәләрне раслаучы документларның кандидат тарафыннан таныкланган күчермәләре;

3) әгәр кандидат фамилиясен, йә исемен, йә атасының исемен үзгәрткән булса, – тиешле документларның кандидат тарафыннан таныкланган күчермәләре;

4) Татарстан Республикасы Рәисенә муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатура турында тәкъдим кертелә торган айның беренче числосына «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда каралган форма буенча кандидатның, аның иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре күләме һәм аларның чыганаклары турында, милек хокукында аларныкы булган мөлкәте турында, шулай ук банклардагы счетлары, кертемнәре, кыйммәтле кәгазьләре турындагы белешмәләр;

5) «Дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, муниципаль районнар башлыкларын, муниципаль округлар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларда кандидатлар тарафыннан, шулай ук Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне Россия Федерациясе Президентына кертүгә бәйле рәвештә сәяси партияләр тарафыннан тапшырыла торган Россия Федерациясе территориясеннән читтәге мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, күчемсез мөлкәт объектлары, транспорт чаралары, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләрнең дөреслеген тикшерү хакында» 2013 елның 6 июнендәге 546 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган форма буенча кандидатныкы, аның иренеке (хатыныныкы) һәм балигъ булмаган балаларыныкы булган Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан күчемсез мөлкәт турында, күрсәтелгән мөлкәт сатып алынган акчаларны алу чыганаклары хакында, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә;

6) «Дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда, муниципаль районнар башлыкларын, муниципаль округлар башлыкларын һәм шәһәр округлары башлыкларын сайлауларда кандидатлар тарафыннан, шулай ук Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне Россия Федерациясе Президентына кертүгә бәйле рәвештә сәяси партияләр тарафыннан тапшырыла торган Россия Федерациясе территориясеннән читтәге мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, күчемсез мөлкәт объектлары, транспорт чаралары, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләрнең дөреслеген тикшерү хакында» 2013 елның

6 июнендәге 546 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән расланган форма буенча, әгәр алыш-биреш суммасы кандидатның һәм аның иренең (хатынының) алыш-биреш башкарылганга кадәр соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, соңгы өч ел эчендә җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча кандидатның, аның иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмә;

7) муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатура турында тәкъдим керткән оешма уставының әлеге оешманың даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан таныкланган күчермәсе;

8) муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатура турында тәкъдим керткән оешманың әлеге оешма уставы нигезендә мондый карар кабул итүгә вәкаләтле органы карарының әлеге оешманың даими эшләүче җитәкче органы тарафыннан таныкланган күчермәсе;

9) кандидатның шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы.

6. Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне алдан карау өчен Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәрне алдан карау комиссиясе (алга таба – комиссия) төзелә.

7. Комиссиянең сан ягыннан һәм персональ составы Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

8. Комиссия әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә тапшырылган документларның һәм белешмәләрнең дөреслеген тикшерүне оештыра, шул исәптән тиешле дәүләт органнарына һәм башка оешмаларга билгеләнгән тәртиптә гарызнамәләр җибәрү юлы белән.

9. Кандидатлар, танышу әңгәмәсен үткәрү өчен, комиссия утырышына чакырылырга мөмкин.

10. Документларны һәм алардагы белешмәләрне тикшерү процессында аларның дөрес булмавы ачыкланган очракта, комиссия кандидатка муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына аның кандидатурасының кире кагылуы турында хәбәр итә.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә кире кагылмаган кандидатларның һәркайсы буенча комиссия тарафыннан рейтинглы тавыш бирү үткәрелә.

12. Рейтинглы тавыш бирү комиссия әгъзалары тарафыннан эзлекле рәвештә кандидатларның һәркайсы буенча аерым-аерым тавыш бирүләрдән гыйбарәт.

13. Рейтинглы тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кимендә ике һәм иң күбе биш кандидат комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе каравына ахыргы карар кабул итү өчен тәкъдим ителә.

14. Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау өчен Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кимендә ике кандидат раслана һәм вәкиллекле органга тәкъдим ителә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы $2^{1}$ өлешенең өченче абзацы (әлеге Закон редакциясендә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгына карата 2027 елның 1 гыйнварына кадәр сайланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының вәкаләтләре срогы беткәнче кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 июнь
№ 45-ТРЗ